**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 4 июнь № 373

г. Казань

Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирлектә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт органында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы һәм «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 30 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирлектә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт органында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирлектә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт органында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау аларны тотуга Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 4 июнь, 373 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирлектә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт органында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау
кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирлектә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт органында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау тәртибен һәм күләмнәрен билгели (алга таба тиешенчә – граждан хезмәткәрләре, дәүләт органы).

2. Яңа хезмәт урыны буенча хезмәт урыныннан бирелә торган торак урын булмаганда торак урынны наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау хокукы граждан хезмәткәрендә түбәндәге шартлар җыелмасы булганда барлыкка килә:

1) граждан хезмәткәре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләнгән;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән билгеләнеш алдыннан граждан хезмәткәре алар буенча ротация каралган граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфаны биләгән;

3) әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән вазыйфаларны биләгәндә граждан хезмәткәре тарафыннан граждан хезмәтен үтү урыннары Татарстан Республикасы чикләрендә төрле урыннарда урнашкан.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслашкан торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы махсуслашкан торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибенең 2 бүлеге нигезендә (алга таба – Торак урыннар бирү тәртибе) хезмәт урыныннан торак урын бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә куелган граждан хезмәткәренә дәүләт органының хезмәт урыныннан торак урыннары булмаганда торак урынны наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнары каплана.

4. Хезмәт урыныннан торак урын бирелү белән бәйле граждан хезмәткәре наемга алган (яңадан наемга алган) торак урыны Торак урыннар бирү тәртибендә куелган таләпләргә җавап бирергә тиеш.

5. Граждан хезмәткәренә торак урынны наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау турында карар хезмәт урынынннан торак урын бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә куелган граждан хезмәткәре түбәндәге документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, аларның күчермәләрен тапшырган көннән соң 7 эш көненнән дә соңга калмыйча дәүләт органы тарафыннан дәүләт органының тиешле актын чыгару юлы белән кабул ителә:

законнар нигезендә төзелгән торак урынны наемга алу (яңадан наемга алу) шартнамәсе;

граждан хезмәткәренең һәм аның гаиләсе әгъзаларының шәхесләрен таныклаучы документлар.

6. Граждан хезмәткәренә торак урынны наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау күләмен исәпләү дәүләт органы тарафыннан Торак урыннар бирү тәртибендә билгеләнгән нормативлардан һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе чикләрендә башка җирлектә урнашкан федераль дәүләт органында федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә билгеләнгән федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрен хезмәт урынынннан торак урыннар белән тәэмин итү һәм әлеге граждан хезмәткәрләренә торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын каплау турында» 2012 ел, 27 октябрь, 1103 нче карары нигезендә ел саен Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы раслый торган Торак урыннар бирү тәртибен һәм торак урынның гомуми мәйданыннан 1 кв.метры өчен наемга алуның (яңадан наемга алуның) чик кыйммәтеннән чыгып гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктлары нигезендә дәүләт органы актында билгеләнгән чыгымнарны кайтару күләменнән артып киткән торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) өчен түләү белән бәйле чыгымнарны граждан хезмәткәре мөстәкыйль үзе түли.

8. Әгәр әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктлары нигезендә дәүләт органы актында билгеләнгән чыгымнарны кайтару күләме торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) өчен түләү белән бәйле чыгымнардан артып китсә, граждан хезмәткәренә чыгымнарны кайтару торак урынны наемга бирүченең банктагы счетына банк хисабы аша акча күчерү юлы белән башкарылган наемга алу (яңадан наемга алу) шартнамәсе буенча түләү турында документлар белән расланган гамәлдәге чыгымнар күләмендә гамәлгә ашырыла.

9. Граждан хезмәткәренә торак урынын наемга алу (яңадан наемга алу) өчен түләү чыгымнарын кайтару граждан хезмәте вазыйфасын биләү турында хезмәт контракты гамәлдә булу чорында башкарыла һәм хезмәт контракты туктатылган көннән соң килүче көннән башлап туктатыла.

Күрсәтелгән акча кайтаруны түләү әлеге Кагыйдәләрнең 8 пункты нигезендә башкарылган түләү турында документларны тапшырган көннән соң бер айдан да соңга калмыйча, граждан хезмәткәре үзе сайлаган банкларның берсендә ачылган банк счетына банк хисабы аша акча күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

10. Граждан хезмәткәре гаиләсе әгъзалары саны кимегәндә һәм нәтиҗәдә торак урынның гомуми саны Торак урыннар бирү тәртибе нигезендә билгеләнгән нормативларга туры килми торган башка шартларда граждан хезмәткәренә башка хезмәт урыны буенча торак урын бирү мөмкинлеге булмаганда башка торак урынны

наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнары әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә, граждан хезмәткәре тиешле гаризаны биргән көннән соң ике айдан да соңга калмыйча кабул ителгән дәүләт органы карары нигезендә кайтарылалар. Башка торак урынны наемга алу (яңадан наемга алу) чыгымнарын кайтару турында карар дәүләт органының тиешле акты белән рәсмиләштерелә.